РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

НИЖНЕШИТЦИНСКИЙ
СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422067, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Нижние Шитцы, ул. Тукая, 15
тел. (84362) 46-4-42

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН ШЫТСУ
АВЫЛ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422067, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Түбән Шытсу авылы, Тукай урамы, 15
тел. (84362) 46-4-42

e-mail: shic.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
27.11.2024

КАРАР
№ 34

Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл
башкарма комитетының 26.01.2022 ел, №1
карары белән расланган торак урыннарына
мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр
кертү турында

РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 15.08.2022 №1415 карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитетының «Торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 26.01.2022 ел, №1 карары белән расланган торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Төзелгән гаризаны формат-логик тикшерү гаризаның электрон рәвешендәге һәр кырын тутыру барышында орган билгели торган таләпләр нигезендә бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал гаризаның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында гаризаның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.»;

1.2. 2.6.1 пунктының 10), 15), 17), 18) пунктчаларында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының

Түбән Шытсу авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shitsi адреслары буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Түбән Шытсу авыл җирлеге башлыгы Б.М.Мәүлетов